МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ**

**БОЕРЫК**

04.08.2022

Казан ш.

№ 488-пр

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмчел хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) эшчәнлеге алып бару өчен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында

1. Тәкъдим ителгән Дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмчел хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) эшчәнлеге алып бару өчен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын расларга.

2. Министр урынбасарларына, идарә башлыкларына хезмәткәрләрне әлеге боерык белән расланган Регламент белән таныштыруны оештырырга һәм аның тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә.

3. 2022 елда Дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмчел хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) эшчәнлеге алып бару өчен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә 2022 елда җир мөнәсәбәтләрен көйләү үзенчәлекләре турында» 2022 елның 9 апрелендәге карары белән билгеләнгән үзенчәлекләрне искә алып тормышка ашырылуын гамәлгә куярга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
04.08.2022 № 488-пр
боерыгы белән расланды

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмчел хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) эшчәнлеге алып бару өчен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмчел хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) эшчәнлеге алып бару өчен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламенты (алга таба – Регламент) Дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмчел хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) эшчәнлеге алып бару өчен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәтен күрсәтү) стандартларын һәм тәртибен билгели һәм Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә кагыла.

1.2. Әлеге Регламент Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{18}$ статьясы (алга таба – РФ ҖК) нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү процедурасын билгели.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге төп этапларны үз эченә ала:

соралган җир кишәрлеген ясарга кирәк булган очракларда җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү;

дәүләт хезмәтендә каралган максатлар өчен җир кишәрлеге бирү.

1.4. Дәүләт хезмәтен алырга гариза бирүчеләр булып РФ ҖК $39^{3}$ статьясының 2 пункты 10 подпункты һәм $39^{6}$ статьясы 2 пункты 15 подпункты нигезендә сатулашулар үткәрмичә генә җир кишәрлеге алу хокукына ия булган гражданнар һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары санала, шул исәптән, соралган

җир кишәрлеген ясарга кирәк булса яки җир кишәрлегенең чикләре ачыклык кертүне сораган очракларда да.

Гариза бирүченең мәнфәгатьләре белән тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләтләр бирелгән зат эш йөртә ала.

1.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә профилирование (гариза бирүчегә дәүләт хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан үткәрелгән анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән гариза бирүче билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү вариантына тәңгәл килгән дәүләт хезмәте күрсәтү) үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү атамасы

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмчел хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) эшчәнлеге алып бару өчен бирү

2.2. Башкарма хакимият органы атамасы

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык).

Дәүләт хезмәте күрсәтүдә хезмәттәшлек турында тиешле килешүе булган очракта, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләр (алга таба – МФЦ) катнаша.

Дәүләт хезмәте күрсәтү физик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр өчен - яшәү урынына яисә фактик яшәгән (торган) урынына карамастан, юридик затлар өчен – урнашкан урынына карамастан экстерриториаль принцип буенча гариза бирүче сайлап алган теләсә кайсы МФЦда башкарыла ала.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган запросны һәм документларны һәм (яки) мәгълүматны кабул итүдән баш тарту турында карар МФЦ тарафыннан әлеге Регламентның 2.7 пункты таләпләренә туры китереп кабул ителә.

2.3 Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

2.3.1.1. Җир кишәрлеген ясарга яки җир кишәрлеге чикләренә ачыклык кертергә кирәк булган очракларда, РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү:

1) җир кишәрлеген бирүгә алдан килешү турында карар;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар (җир кишәрлеген бирүгә алдан килешүдән баш тарту турында карар).

2.3.1.2. Җир кишәрлеген РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә дәүләт хезмәтендә каралган максатларда милеккә, арендага биргәндә (җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында карар булса):

1) җир кишәрлеген милеккә бирү турында карар, җир кишәрлеген сату-алу шартнамәсе (алга таба – сату-алу шартнамәсе);

2) җир кишәрлеген арендага бирү турында карар, җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе (алга таба – аренда шартнамәсе);

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар (җир кишәрлеген милеккә бирүдән баш тарту турында карар, җир кишәрлеген арендага бирүдән баш тарту турында карар).

2.3.2. Реестр язуы дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып тормый.

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе нинди дә булса Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмати системасында теркәлми.

2.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе гариза бирүчегә "Электрон имза турында" 2011 елның 6 апрелендәге № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба - Федераль закон № 63-ФЗ) таләпләренә туры китереп көчәйтелгән электрон имза белән министр тарафыннан (җир кишәрлеген милеккә тапшырган очракта), министрның беренче урынбасары тарафыннан (җир кишәрлеге арендага бирелгәндә) имзаланган электрон документлар рәвешендә Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы (https://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика порталы) гариза бирүченең шәхси кабинетына юллана.

2.3.5. Гариза бирүче сайлавы буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе Министрлыктан җибәрелгән, кәгазьгә бастырылган, МФЦ мөһере һәм МФЦ хезмәткәре имзасы белән расланган электрон документ экземпляры формасында МФЦ аша алынырга мөмкин.

2.3.6. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында яки электрон документның кәгазь экземпляры формасында алырга мөмкин.

2.3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе сыйфатында гариза бирүче җир кишәрлеген бирүгә алдан килешү турында карарны яки җир кишәрлеген милеккә бирү турында карар белән сату-алу шартнамәсен (җир кишәрлеген арендага бирү турында карар белән аренда шартнамәсе) яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карарны (җир кишәрлеген бирүгә алдан килешүдән баш тарту турында карар яки җир кишәрлеген милеккә бирүдән баш тарту турында карар, җир кишәрлеген арендага бирүдән баш тарту турында карар) Министрлыктан шәхсән үзе алырга мөмкин.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы

2.4.1. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар гариза бирүче тарафыннан почта аша юлланылган яки шәхси тапшырылган булса, дәүләт хезмәте гариза һәм документлар регистрацияләнгән көннән соң 19 эш көне эчендә күрсәтелә.

2.4.2. Гариза бирүче гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны Республика порталында гариза бирүченең шәхси кабинеты аша тапшырса, эш номенклатурасына туры китереп гаризага Республика порталының шәхси кабинетында (алга таба – шәхси кабинет) күренеп торган номер һәм «Документларны тикшерү» статусы бирелгәннән соң дәүләт хезмәте Министрлык тарафыннан 19 эш көне эчендә күрсәтелә.

2.4.3. Гариза бирүче гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны гариза МФЦ аша тапшырган икән, Министрлык тарафыннан дәүләт хезмәте гариза һәм документлар регистрацияләнгәннән соң 19 эш көне эчендә күрсәтелә, шулай ук, МФЦ Регламенты белән каралган срок та искә алына.

2.4.4. Гариза бирүченең аренда шартнамәсе яки җир кишәрлеген сату-алу шартнамәсен имзалау вакыты дәүләт хезмәте күрсәтү срогына керми.

2.4.5. Министрлыкка РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында гариза кергән датада Министрлык карамагында башка зат тарафыннан тапшырылган җир кишәрлеге схемасы булып, әлеге схемада каралган җир кишәрлекләренең урнашуы өлешчә яки тулысынча туры килгән очракта, алдарак җибәрелгән яки бирелгән җир кишәрлеге схемасын раслау турында карар кабул иткәнчегә кадәр яисә күрсәтелгән схеманы раслаудан баш тарту турында карар кабул ителгәнчегә кадәр, дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылып торыла.

2.4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү җир кишәрлеген хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗы өчен бакчачылык, крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлеге бирелү турында белдерү (алга таба – белдерү) басылып чыкканнан соң 30 көнгә туктатылып торыла.

2.4.7. Җир кишәрлеге ясаласы җир кишәрлеге схемасы «Россия Федерациясе Җир Кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге № 137-ФЗ Федераль законның (алга таба - № 137-ФЗ Федераль закон) $3^{5}$ статьясы нигезендә килештерелергә тиеш булган очракларда әлеге Регламентның 2.4.1, 2.4.2, 2.4.3 пунктларында каралган срок $3^{18}$ статьясы нигезендә җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында гариза кергән көннән 45 көннән дә артык булмаган срокка кадәр озайтылырга мөмкин.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Республика порталында һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәрендәге рәсми сайтында (http://mzio.tatarstan.ru)

түбәндәгеләр урнаштырыла:

дәүләт хезмәте күрсәтүне көйләүче норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмә;

дәүләт хезмәте күрсәтүче Министрлыкның һәм Министрлыкның вазыйфаи затының карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларның тулы исемлеге

2.6.1. Дәүләт хезмәте алу өчен гариза бирүче мөрәҗәгатенең категориясенә һәм нигезенә карамастан, гариза тапшыра:

- МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткән очракта кәгазь документ рәвешендә;

- Республика порталы аша мөрәҗәгать итсә, электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләрне кертү юлы белән тутырыла), әлеге Регламентның 2.6.5 пункты таләпләренә туры китереп имзалана.

2.6.2. Гариза бирүче Министрлыкка РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза (әлеге Регламентка 1 нче кушымта) белән мөрәҗәгать иткәндә түбәндәге документларны тапшыра:

1. Гариза бирүченең РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә җир кишәрлеге алу хокукларын раслаучы, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтләр бирелгән башкарма хакимият федераль органы билгеләгән документлар, Министрлыкка ведомствоара мәгълүмати арадашлык тәртибендә бирелә торган документлар (гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча алу хокукын раслаган Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча алу хокукын раслаучы документларны раслау турында» 2020 елның 2 сентябрендәге № П/0321 Боерык белән расланган документлар исемлегендә каралган документлар, дәүләт хакимиятнең вәкаләтле федераль органыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимитяе органыннан, җирле үзидарә органыннан) чыгарылма булып тора.

2. Соралган җир кишәрлеген ясарга кирәк булган очракта, чикләрендә шул җир кишәрлеге ясаласы территориянең ызанлау проекты булмаса, җир кишәрлегенең урнашу схемасы.

3. РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза белән гариза бирүченең вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүченең вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ.

2.6.3. Гариза бирүче Министрлыкка җир кишәрлеген РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә дәүләт хезмәтендә каралган максатларда милеккә, арендага бирү турында гариза (әлеге Регламентка 2 нче кушымта) белән мөрәҗәгать иткәндә түбәндәге документларны тапшыра:

1. Гариза бирүченең РФ ЖК 39[18] статьясы нигезендә җир кишәрлеге алу хокукларын раслаучы, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтләр бирелгән башкарма хакимият федераль органы билгеләгән документлар, Министрлыкка ведомствоара мәгълүмати арадашлык тәртибендә бирелә торган документлар (гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча алу хокукын раслаган Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча алу хокукын раслаучы документларны раслау турында» 2020 елның 2 сентябрендәге № П/0321 Боерык белән расланган документлар исемлегендә каралган документлар, дәүләт хакимиятнең вәкаләтле федераль органыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимитяе органыннан, җирле үзидарә органыннан) чыгарылма булып тора.

2. Физик зат булган гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) яисә физик яки юридик зат вәкиленең шәхесен раслаучы документ күчермәсе.

3. РФ ЖК 39[18] статьясы нигезендә җир кишәрлеген милеккә, арендага бирү турында гариза белән гариза бирүченең вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүченең вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ.

Күрсәтелгән документлар Министрлыкка җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза белән җибәрелгән булса, аларны карау нәтиҗәләре буенча җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителгән очракта күрсәтелгән документларны тапшыру таләп ителми.

2.6.4. Гариза һәм аңа теркәлгән документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырыла (юллана) ала:

1) шәхсән (ышанычнамә нигезендә гариза бирүче исеменнән эш йөрткән зат) яки кәгазь документлар рәвешендә почта элемтәсе аша. Гариза һәм аңа теркәлгән документлар почта аша юлланган очракта тиешле тәртиптә раслана;

2) МФЦ аша кәгазь документлар рәвешендә;

3) Республика порталы аша электрон формада.

2.6.5. Физик затлар гаризаны һәм кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргәндә гаризага гади электрон имза куялар.

Гариза бирүчегә гади электрон имза алу өчен Электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмати системаларның мәгълүмати-технологик арадашлыгын тәэмин итүче инфраструктурада идентификация һәм аутентификациянең бердәм системасында (алга таба – ЕСИА) регистрация (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук учет язуын стандарттан да ким булмаган дәрәҗәдә расларга кирәк.

Россия Федерациясе территориясендә регистрацияләнгән юридик затлар (крестьян (фермер) хуҗалыклары) һәм юридик затларның вәкилләре гаризаны һәм кирәкле документларны Бердәм портал, Республика порталы аша юллаганда гаризаны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалыйлар.

Гариза бирүче вәкиленең электрон документ (документның электрон образы) рәвешендәге ышанычнамәсе әлеге документларны ясау һәм имзалау вәкаләте булган затларның, шул исәптән, нотариусларның тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән раслана.

Гаризага теркәлгән электрон документлар (документның электрон образы), шул исәптән, ышанычнамәләр 50 Мбайттан да артык булмаган үлчәмдәге pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf форматрлы файллар рәвешендә җибәрелә.

Тапшырылган электрон документларның (документларның электрон образы) сыйфаты документ текстын тулысынча укырга һәм документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш.

2.6.6. Гаризаны ышанычнамә буенча формалаштырганда вәкаләтле зат паспортын (шәхесен раслаучы башка документ), нотариаль расланган ышанычнамә яки законнарга таянып нотариаль расланганга тиңләштерелгән ышанычнамә бирелә.

Гаризага беркетелгән документлар нотариаль раслана ала. Нотариаль расланган күчермә булмаган очракта түбәндәгеләр шул ук дәрәҗәдә кабул ителергә тиеш:

төп нөсхәгә туры килүе турында оешма җитәкчесе яисә шул вазыйфага вәкаләтле зат имзалаган һәм оешма мөһере (булса) куелган документ күчермәсе;

документның төп нөсхәсе күрсәтелгән очракта расланмаган күчермәләр. Бу очракта документ күчермәсен аны кабул итүче раслый.

2.6.7. Ведомствоара мәгълүмати арадашлык кысаларында алына торган документлар:

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати арадашлык кысаларында түбәндәгеләр алына:

Министрлыкка РФ ЖК $39^{18}$ статьясы нигезендә җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә:

1. Җир кишәрлеге турында ТР буенча Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба - ЕГРН) өземтә.

2. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан юридик зат турында өземтә, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба – ТР буенча ФСХИ).

Министрлыкка җир кишәрлеген РФ ЖК $39^{18}$ статьясы нигезендә дәүләт хезмәтендә каралган максатларда милеккә, арендага бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә:

1. Җир кишәрлеге турында ЕГРН өземтә, ТР буенча Росреестрдан.

2. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан юридик зат турында өземтә (ТР буенча ФСХИдан).

3. Гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча алу хокукын раслаган Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча алу хокукын раслаучы документларны раслау турында» 2020 елның 2 сентябрендәге № П/0321 Боерык белән расланган документлар исемлегендә каралган башка документлар, дәүләт хакимиятнең вәкаләтле федераль органыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органыннан, җирле үзидарә органыннан.

2.6.8. Гариза бирүче Регламентның 2.6.7 пунктта күрсәтелгән документларны (белешмәләрне) Бердәм портал, Республика порталы аша биргәндә әлеге документларны булдыру һәм имзалау өчен вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле имзасы куелган электрон документ формасында бирә ала яки МФЦга кәгазь формасында.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1. Әлеге Регламентның 2.6.2 һәм 2.6.3 пунктларында күрсәтелгән, үезмәт күрсәтү өчен зарури булган документлар комплектының тулысынча тапшырылмаган.

2. Кәгазь документларда бозылган урыннар булуы мәгълүматны һәм белешмәне тулы күләмдә кулланырга, текстны укырга һәм (яки) документның реквизитларын танырга мөмкинлек бирми.

3. Гариза һәм башка документлар аларны тапшыру вәкаләтләре булмаган зат тарафыннан тапшырылган.

4. Кәгазь документларда законнарда билгеләнгән тәртиптә расланмаган чистартулар, төзәтүләр бар.

5. Әлеге Регламентның 1.4 пунктында күрсәтелгән гариза бирүчеләр категориясенә кермәгән зат мөрәҗәгать иткән.

6. Документлар дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән вакытка көчен югалткан.

7. Министрлыкка электрон документ форматында тапшырылган гариза һәм документларның (документларның күчермәләре) «Территориянең кадастр планында җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре урнашу схемасын раслау турында, дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген сату буенча аукцион үткәрү яисә дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлегенә аренда килешүе төзү хокукына аукцион үткәрү турында, дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү турында алдан килешү турында, дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү турында гариза бирү ысулларын һәм тәртибен раслау турында һәм дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген, шәхси

милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрен кулланып гариза бирү, шулай ук аларның форматларына куелган таләпләр турында» 14.01.2015, № 7 Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгына (алга таба – Боерык № 7) туры килмәве, № 63-ФЗ Федераль закон һәм “Дәүләти һәм муниципаль хекзмәтләрне күрсәтүне оештыру турында” 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба - № 210-ФЗ Федераль закон) таләпләре нигезендә электрон имза куелмаган булуы.

8. Көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның гамәлдә булуын тану өчен № 63-ФЗ Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән шартларның үтәлмәве.

9. Гариза формасында мәҗбүри юлларның дөрес тутырылмавы (ышанычлы, тулы, яки дөрес түгел), шул исәптән, Республика порталындагы гаризаның интерактив формасын да

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Министрлыкка РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында гариза кергән датада Министрлык карамагында башка зат тарафыннан тапшырылган җир кишәрлеге схемасы булып, әлеге схемада каралган җир кишәрлекләренең урнашуы өлешчә яки тулысынча туры килгән очракта, алдарак җибәрелгән яки бирелгән җир кишәрлеге схемасын раслау турында карар кабул иткәнчегә кадәр яисә күрсәтелгән схеманы раслаудан баш тарту турында карар кабул ителгәнчегә кадәр, дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылып торыла.

2.8.2. Министрлыкка РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә җир кишәрлеген милеккә, арендага бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗы өчен бакчачылык, крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлеге бирелү турында белдерү (алга таба – белдерү) басылып чыкканнан соң 30 календарь көненә туктатылып торыла.

2.8.3. Җир кишәрлеге ясаласы җир кишәрлеге схемасы «Россия Федерациясе Җир Кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге № 137-ФЗ Федераль законның (алга таба - № 137-ФЗ Федераль закон) $3^5$ статьясы нигезендә килештерелергә тиеш булган очракларда әлеге Регламентның 2.4.1 пунктында каралган срок РФ ҖК $3^{18}$ статьясы нигезендә җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында гариза кергән көннән 45 көннән дә артык булмаган срокка кадәр озайтылырга мөмкин.

2.8.4. Түбәндәге шартларның берсенең генә булса да булуы дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

РФ ҖК $3^{18}$ статьясы нигезендә җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә:

1) җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында гаризага беркетелгән җир кишәрлегенең урнашу схемасы РФ ҖК $10^{10}$ статьясының 16 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча раслана алмый;

2) ясаласы җир кишәрлеге гариза бирүчегә РФ ҖК $39^{16}$ статьясының 1 – 13, 15 – 19, 22 һәм 23 подпунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча гариза бирүчегә бирелә алмый;

3) № 218-ФЗ Федераль закон нигезендә чикләре ачыкланырга тиешле җир кишәрлеге РФ ҖК $39^{16}$ статьясының 1 - 23 подпунктларында күрсәтелгән шартлар буенча гариза бирүчегә бирелә алмый;

4) белдерү басылганнан соң утыз көн эчендә Министрлыкка башка гражданнардан, крестьян (фермер) хуҗалыкларыннан аукционда катнашу нияте турында гаризалар керүе.

Министрлыкка РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә җир кишәрлеген милеккә, арендага бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә:

1) белдерү басылганнан соң утыз көн эчендә Министрлыкка башка гражданнардан, крестьян (фермер) хуҗалыкларыннан аукционда катнашу нияте турында гаризалар керүе;

2) әлеге Регламентның 3 кушымтасында күрсәтелгән шартларның берсенең генә булса да булуы.

2.8.5. Баш тарту сәбәпләре күрсәтелгән кәгазьгә чыгарылган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карарга министр урынбасары имза куя һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне гариза бирүчегә һәм (яки) МФЦга юллана.

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алырга Республика порталы ашы мөрәҗәгать итсә, шәхси кабинетка автомат рәвештә министр урынбасарының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның электрон образы җибәрелә.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган түләүнең күләме һәм алу ысуллары

Республика порталын, рәсми сайтны кулланып дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасы һәм Россия Федерациясе законнарына таянып башка түләүләр алынмый. Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы

Дәүләт хезмәте алу өчен гариза биргәндә максималь көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда алдан язылу буенча килеп чиратны максималь көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләренә чират тәртипләре билгеләнмәгән.

2.11. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сораган гариза бирүченең запросын регистрацияләү срогы

2.11.1. Гариза һәм документлар кергән бер көн эчендә.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә регистрацияләнә.

Гариза бирүче яки аның вәкиле тарафыннан МФЦ аша бирелгән гариза Министрлык тарафыннан МФЦдан кергән көнне регистрацияләнә.

2.11.2. Гариза бирүче МФЦга шәхсән үзе мөрәҗәгать итсә, шул көнне аңа АИС МФЦдан гаризаның җибәрелүенраслаган һәм электрон гариза бирү датасы күрсәтелгән теркәү номерлы расписка бирелә.

2.11.3. Гариза Республика порталы аша юлланса, гариза бирүче гариза бирелгән көнне Республика порталындагы шәхси кабинетына һәм электрон почта белән гаризаның җибәрелүен раслаган, гариза бирү датасы күрсәтелгән теркәү номерлы белдерү ала.

2.11.4. Министрлык дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны әлеге документларның кәгазь версиясен китермичә генә кабул итүне һәм запросны регистрацияләүне тәэмин итә.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелү Министрлыкның янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган бинасында һәм бүлмәләрендә башкарыла.

Гариза берүчеләрне кабул итү урыннарына документлар тутыру өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар урнаштырыла.

Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына каршылыксыз керә алуы тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү).

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текст форматында һәм мультимедиалы мәгълүмат гариза бирүчегә уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән, инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән булуы да күздә тотыла.

2.12.2. Инвалидларны, шул исәптән, кресло-арба һәм озатып йөрүче эт кулланучыларны, объектларга үтеп керү һәм хезмәт алу мөмкинлеге белән тәэмин итү чаралары гамәлгә ашырыла. Моңа түбәндәгеләр дә керә:

бинага һәм бүлмәләргә, шулай ук, аларда күрсәтелгән хезмәтләргә каршылыксыз үтү шартлары;

министрлык территориясе буйлап мөстәкыйль хәрәкәт итү, миинстрлык бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу мөмкинлеге, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән, кресло-арба кулланып;

күз күреме һәм мөстәкыйль йөри алу функцияләре бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән булуны исәпкә алып, бинага, бүлмәләргә каршылыксыз керә алу һәм хезмәт күрсәтү мөмкинлеге өчен зарури җайланмаларны һәм мәгълүмат чыганакларын уңайлы урыннарда урнаштыру;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге № 386н боерыгы белән расланган «Озатучы этнең махсус өйрәтелгәнен раслаучы документ формасын раслау турында, һәм аны бирү тәртипләре» белән күрсәтелгән формада һәм тәртипләрдә махсус өйрәтелгәнлеген раслаучы документ булса, озатучы этне бинага һәм бүлмәләргә кертү;

министрлык хезмәткәрләренең инвалидларга башкалар белән бертигез дәүләт хезмәте алырга комачаулаган каршылыкларны үтәргә ярдәм итүе.

2.12.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларга инвалидлар керүне тәэмин итү таләпләре һәм дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла торган чаралар 2016 елның 1 июленнән соң эксплуатациягә кертелгән яки модернизацияләнгән, реконструкцияләнгән биналарга карый.

2.13. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) документлар кабул ителә һәм тапшырыла торган биналарының җәмәгать транспортына якын булуы;

2) кирәк кадәр санда белгечләрнең, шулай ук, гариза бирүчеләрнең документларын кабул итә торган урыннарның булуы;

3) мәгълүмати стендларда, министрлыкның рәсми сайтында, Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүматның булуы;

4) гаризаны электрон рәвештә бирү ммөкинлеге

5) министрлык бинасын һәм бүлмәләрне инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелгән бүлмәләргә каршылыксыз үтү мөмкинлеге тудыра торган чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин итү, шулай ук, инвалидларга дәүләт хезмәте алуны тәэмин итүче башка шартларны үтәү;

6) министрлык хезмәткәрләренең инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтелү өчен бүлмәләргә каршылыксыз үтү белән бәйле булмаган башка киртәләрне үтәргә булышуы.

2.13.2. Дәүләт хезмәтенең сыйфаты күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) документларны кабул итү һәм карау срогының саклануы;

2) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогының саклануы;

3) министрлык хезмәткәрләренең әлеге Регламентны бозулары турында нигезле шикаятьләрнең булмавы;

4) Министрлык бинасының, дәүләт хезмәте күрсәтү бүлмәләренең инвалидлар керү өчен уңайлы булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү ачыклыгы күрсәткечләренә ирешү.

5) гариза бирүченең министрлыкның вазыйфаи затлары белән үзара бәйләнешләр саны (консультацияләрне исәпкә алмаганда):

кирәкле документлар белән бергә гариза биргәндә бер тапкыр;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документның кәгазь версиясен алганда бер тапкыр.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән гариза бирүченең аралашу вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмасы ярдәмендә, Республика порталын, терминаль җайланмаларны кулланып бәяли ала.

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турындагы мәгълүматны гариза бирүче Республика порталында шәхси кабинет аша, МФЦ аша алырга хокуклы.

2.13.4. Дәүләт хезмәте гариза бирүченең яшәү урынына яки фактик торган урынына карамастан, үзе сайлаган теләсә кайсы МФЦда экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә.

Гариза бирүче дәүләт хезмәтен комплекслы запрос составында алырга мөмкин.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле башка таләпләр, шул исәптән:

дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәкләрдә күрсәтү үзенчәлекләрен һәм дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алып;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мәгълүмат алу турында.

2.14.1. Зарури һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми.

2.14.2. Гариза бирүче Министрлыкның Дәүләт җирләрен нәтиҗәле файдалану бүлегенә (алга таба – Бүлек) шәхсән үзе, телефон аша һәм (яки) электрон почта аша, почта аша мөрәҗәгать иткәндә консультация бирелә.

2.14.3. Дәүләт хезмәте гариза бирүченең яшәү урынына яки фактик торган урынына карамастан, үзе сайлаган теләсә кайсы МФЦда экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә.

2.14.4. Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелгәндә гариза бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) дәүләт хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алу;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган башка документларны, шул исәптән электрон образлары «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр оештыру турында» № 210-ФЗ Федераль законның 16 статьясының $7^2$ пунктындагы 1 кисәгенә туры китереп алдарак расланган документлар һәм мәгълүматны Республика порталы аша тапшыру;

в) дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон формада бирелгән гаризаның үтәлеше турында белешмә алу;

г) хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләү;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алу;

е) Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата дәүләт хезмәте күрсәтү органнарының, аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү процессын тәэмин итүче Республика порталы, федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша шикаять итү.

Гариза формалаштыру Республика порталында электрон формада гариза тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла, башка төрле формада өстәмә гаризалар бирү зарурлыгы юк.

2.14.5. Гариза формалаштырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган гариза һәм башка документларны күчерү һәм саклау мөмкинлеге;

2) берничә гариза бирүченең бердәм гариза юллавы күзалланган хезмәтләр буенча мөрәҗәгать иткәндә берничә гариза бирүче тарафыннан гаризаның бер электрон формасын тутыру мөмкинлеге;

3) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьгә бастыру мөмкинлеге;

4) гариза бирүченең электрон формага алдарак керткән билгеләрен гариза бирүче теләге белән теләсә кайсы мизгелдә саклау мөмкинлеге, шул исәптән, кертү хаталары киткәндә һәм электрон формага әйләнеп кайтып билгеләрне кабат кертү зарурлыгы туганда;

5) гаризаның электрон форма юлларын ЕСИАга урнаштырылган белешмәне кулланып, Республика порталындагы белешмәне кулланып кертә башлаганчы кертә алу, шул исәптән, идентификация һәм аутентификация бердәм системасында булмаган белешмәләргә кагылышлысын да;

6) алдан кертелгән мәгълүматны югалтмыйча электрон форманы тутыруның теләсә кайсы этабына әйләнеп кайту;

7) гариза бирүченең бер ел дәвамында алдан бирелгән гаризаларга керә алуы, шулай ук, 3 ай дәвамында - өлешчә формалаштырылган гаризаларга да.

2.14.6. Гариза бирүчеләрнең Министрлыкка, МФЦга кабул ителүгә язылуы (алга таба – язылу) Республика порталы, Министрлык телефоны, МФЦның контакт үзәге аша башкарыла.

Гариза бирүче күпфункцияле үзәкнең кабул итү графигы чикләрендә билгеләнгән теләсә кайсы бу датада һәм вакытта язылу мөмкинлеге бирелә.

Алдан язылганда гариза бирүче хәбәр иткән мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматка туры килмәсә, алдан язылу юкка чыгарыла.

Алдан язылганда гариза бирүчегә раслау талонын бастыру мөмкинлеге бирлә. Гариза бирүче электрон почта адресын хәбәр итсә, алдан язылу датасы, вакыты һәм урыны күрсәтелгән мәгълүмат аның почтасына юллана.

Алдан язылганда гариза бирүчегә билгеләнгән вакытка 15 минутка соңга калса, алдан язылган вакыт юкка чыгарылуы турында хәбәр ителә.

Гариза бирүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Гариза бирүчедән Россия Федерациясе хокукый актларына туры китереп идентификация һәм аутентификация үтүдән, кабул ителү максатын күрсәтүдән тыш, шулай ук, кабул итү өчен кирәкле вакыт интервалын броньлау өчен кирәкле мәгълүматтан башкасын таләп итү тыела.

2.14.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртипләре турында мәгълүмат Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла.

Язма мөрәҗәгать буенча Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы хезмәткәре гариза бирүчегә язмача җентекләп дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен аңлата, законнарда билгеләнгән срокларда гариза бирүчгә җавапны җибәрә. Мөрәҗәгать ителгән телдә җавап бирү мөмкинлеге булмаган очракта Татарстан Республикасының дәүләт телләре кулланыла.

2.14.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә “Бердәм ведомоствоара электрон аралашлык системасы” федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы һәм ясалган реестр язуларындагы ялгышларны һәм хаталарны төзәтү өчен кирәкле дәүләт хезмәте күрсәтү вариантларын да кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары исемлеге

Дәүләт хезмәте, шулай ук, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы һәм ясалган реестр язуларындагы ялгышларны һәм хаталарны төзәтү бер вариантта башкарыла һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең хезмәт күрсәтү сроклары, гариза бирүчеләр категорияләре, түләү зурлыгы һәм тәртибе, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар исемлегенең аерым сценарииләре юк; документлар һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә килеп чыккан юридик гамәлләр аерылмый.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документ дубликаты бирү өчен вариантлар исемлеге, шул исәптән, андый дубликат бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документ дубликатын бирү бер вариантта башкарыла һәм хезмәт күрсәтү сроклары, гариза бирүчеләр категорияләре, түләү зурлыгы һәм тәртибе, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар исемлегенең аерым сценарииләре юк; документлар һәм дубликат бирү нәтиҗәсендә килеп чыккан юридик гамәлләр аерылмый.

Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документ дубликатын бирүдән баш тарту өчене нигезләр юк.

3.3. Гариза бирүченең профилирование административ процедурасын тасвирлау

Гариза бирүченең профилирование процедурасы гамәлгә ашырылмый.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы.

1) гариза бирүчегә консультация, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тутыру буенча да;

2) гариза бирүче тапшырган документлар комплектын кабул итү һәм карап чыгу;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

4) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру;

7) дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсе булган документларда киткән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү.

3.5. Гариза бирүчегә консультация, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тутыру буенча да

3.5.1. Административ процедура үтәлә башлауга нигез булып гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгате тора.

Административ процедура үтәлеше өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр):

- МФЦга мөрәҗәгать иткәндә – МФЦ хезмәткәре;

- Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә – Бүлек хезмәткәре.

3.5.2. Гариза бирүче дәүләт хезмәтен алу тәртибе һәм сроклары турында консультацияләр алу өчен МФЦга шәхсән, телефоннан, һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

МФЦ хезмәткәре гариза бирүчегә тапшырыласы документациянең составы, формасы һәм дәүләт хезмәте тутыру өчен кирәкле башка сораулар буенча мәгълүмат бирә.

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүматны МФЦ сайтына http://mfc16.tatarstan.ru кереп алырга да мөмкин.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә үтәлә.

Административ процедуралар башкарылу нәтиҗәсе: тапшырылырга тиешле документациянең составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле башка сораулар буенча консультацияләр.

3.5.3. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында, шул исәптән, дәүләт хезмәте алу өчен тапшырыласы документация һәм башка сораулар буенча Министрлыкка шәхсән, телефон аша һәм (яки) электрон почта, почта аша мөрәҗәгать итеп, шулай ук, Бердәм портал, Республика порталы, Министрлык сайтында консультация алырга мөмкин.

3.5.4. Министрлык хезмәткәре гариза бирүчене дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, Министрлыкның урнашкан урыны, белешмә телефоннары, эш сәгатьләре, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гаризалар кабул итү графигы турында мәгълүмат бирә һәм гариза бирүчегә ярдәм итә, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны формалаштыру буенча да.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар мөрәҗәгать кергән көннән башлап, Министрлыкның Эш башкару буенча инструкциясендә билгеләнгән срокларда үтәлә.

Административ процедуралар башкарылу нәтиҗәсе: тапшырылырга тиешле документациянең составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле башка сораулар буенча консультацияләр.

3.6. Гариза бирүче тапшырган документлар комплектын кабул итү һәм карап чыгу

3.6.1. Гариза бирүче дәүләт хезмәте алу өчен МФЦга мөрәҗәгать итергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү экстерриториаль принцип буенча яшәү урынына яисә фактик яшәгән (торган) карамастан, гариза бирүче сайлап алган теләсә кайсы МФЦда башкарыла. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен әлеге Регламентның 2.6.2, 2.6.3 пунктларында күрсәтелгән документларны МФЦ аша кабул итү тиешле тәртиптә кабул ителгән МФЦ Регламентына һәм Килешүгә туры китереп башкарыла.

Техник мөмкинелекләр булганда кирәкле документлар электрон рәвештә (документларның ЭЦП МФЦда имзаланган скан-образлары) МФЦның мәгълүмати системасы аша тапшырыла. Бу очракта документлар Министрлыкка Килешүдә күрсәтелгән даимилек белән җибәрелә.

Гариза һәм документларны гариза бирүченең вәкиле тапшыра ала.

3.6.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар Бердәм портал, Республика порталы аша электрон формада кабул ителә.

3.6.2.1. Министрлык хезмәткәре гариза Республика порталы аша бирелгәндә 1 эш көне эчендә, гариза ял яки бәйрәм көнендә керсә – беренче эш көнендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итә, гариза бирүчегә гаризаның килүе турында электрон хәбәр юллый;

б) гаризаны регистрацияли һәм гариза бирүчегә гаризаның регистрацияләнүе турында яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү юллый.

Гариза керүе турында электрон хәбәр һәм гаризаның регистрацияләнүе турында белдерү Республика порталындагы шәхси кабинетта үтенеч язуы каралу статусында автомат рәвештә чагыла.

3.6.2.2. Гариза бирүче Республика порталы аша электрон формада гариза бирү өчен түбәндәге гамәлләрне кыла:

Республика порталында авторизация үтә;

Республика порталында электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри белешмәләр кертелә торган электрон гариза формасын тутыра;

электрон гариза формасына электрон рәвештәге документларны яки документларның электрон образларын беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм ризалашу фактын раслый (электрон гариза формасына ризалык турында тиешле билгене куя);

хәбәр ителгән мәгълүматларның дөреслеген раслый (электрон гариза формасына тиешле билгене куя);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасында тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.6.5 пункты таләпләренә туры китереп имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Регламентның әлеге пункты белән билгеләнгән процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Административ процедуралар башкарылу нәтиҗәсе: электрон арадашлык системасы ярдәмендә Министрлыкка җибәрелгән электрон эш.

Формалаштырылган запросны формат һәм логик яктан тикшерү гариза бирүче запросның электрон формасындагы һәр юлны тутырганнан соң автомат рәвештә башкарыла. Запросның электрон формасындагы юлның дөрес тутырылмавы ачыкланса, гариза бирүчегә запросның электрон формасы өстендә үк мәгълүмати хәбәр буларак, ачыкланган ялгыш һәм аны төзәтү тәртибе турында белдерелә.

3.6.2.3. Контроль бүлеге хезмәткәре Республика порталыннан килгән электрон гаризаларның барлыгын тикшерә, көнгә ике тапкырдан да ким булмаган вакытта кергән гаризаларны һәм беркетелгән документларның электрон образларын (документларны) карап чыга.

Эш номенклатурасына туры китереп гаризага номер һәм «Документларны тикшерү» статусы бирә, Республика порталының шәхси кабинетында автомат рәвештә чагыла.

Контроль бүлеге хезмәткәре карау өчен документлар кергәч:

электрон формада кергән эшләрне, шул исәптән гариза бирүче беркеткән электрон рәвешле документларны һәм документларның электрон образларын карап чыга;

документларның электрон образларының комплектлылыгын, укылышын тикшерә;

Республика порталына мөрәҗәгать итеп электрон имзаның гамәлдә булу шартларының саклануын тикшерә (гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган документларның электрон образлары бирелгән очракта).

Бүлек белгече әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта дәүләт хезмәте күрәстү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты әзерли.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тикшерү нәтиҗәсендә аның гамәлдә булу шартларының сакланмавы ачыкланса, баш тарту турында карар проекты әлеге карарны кабул итүгә нигез булган № 63 Федераль законның 11 статьясы пунктларын үз эченә алырга тиеш.

Баш тарту сәбәпләре күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты (дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре әлеге документларга билгеләнгән таләпләрне бозу белән бәйле булган очракта, документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре тапшырылмаган документларның атамасы (мәгълүмат, белешмә), дөрес булмаган һәм (яки)

каршылыклы мәгълүмат, тиешле тәртипләрнең бозып формалаштырылган) электрон арадашлык системасы аша тиешле тәртиптә килештерүгә юллана.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын килештерү Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының Эш башкару инструкциясендә каралган тәртиптә башкарыла.

3.6.2.4. Әлеге Регламентның 3.6.2.3 пунктында күрсәтелгән процедураларны башкару, техник мөмкинлекләр булганда, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрәстү өчен тәгаенләнгән автоматлаштырылган мәгълүмати системаны кулланып, автоматик режимда башкарыла.

3.6.3. Министрлыкка документарь формада гариза бирүчедән кергән документлар комплектын карап чыгу.

Контроль бүлеге белгече гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавын тикшерә. Тикшерү Бүлек белгече катнашында башкарыла;

әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта гаризаны һәм беркетелгән документларны теркәп, карау өчен Бүлеккә юллый;

әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта документларны теркәмичә генә, Бүлек белгече документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен аңлаткан язу белән, гариза бирүчегә кайтара.

Гариза бирүче документларның расланмаган күчермәләрен тапшырган очракта, Бүлек белгече оригиналга карап документларның күчермәләрен чагыштыра һәм үз имзасы белән раслый.

Әлеге регламентның 3.6.2 пункты билгеләгән процедуралар гариза һәм документлар кергән көндә гамәлгә ашырыла.

Административ процедуралар башкаруның нәтиҗәсе: карау өчен кабул ителгән документлар комплекты яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган документларны кабул итүдән баш тарту карары проекты, яки гариза бирүчегә кайтарылган документлар.

3.6.4. Документлар Министрлыкка почта аша документарь формада кергән очракта контроль бүлеге хезмәткәре: гаризаны һәм документларны карап, документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта гаризаны һәм беркетелгән документларны регистрацияли;

әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта документларны регистрацияләмичә генә, документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен ачыклап Бүлеге белгече әзерләгән аңлатма белән, гариза бирүчегә кайтара.

Гариза бирүче документларның расланмаган күчермәләрен тапшырган очракта, Бүлек белгече оригиналга карап документларның күчермәләрен чагыштыра һәм үз имзасы белән раслый.

Әлеге пункт билгеләгән процедуралар гариза һәм документлар кергән көннән биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедуралар башкаруның нәтиҗәсе: карау өчен кабул ителгән яки сәбәпләре күрсәтелеп гариза бирүчегә кайтарылган документлар комплекты.

3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору

3.7.1. Министрлыкка РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (алга таба – туктатып тору).

3.7.1.1. Министрлыкка РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында гариза кергән датада Министрлык карамагында башка зат тарафыннан тапшырылган җир кишәрлеге схемасы булып, әлеге схемада каралган җир кишәрлекләренең урнашуы өлешчә яки тулысынча туры килгән очракта, алдарак җибәрелгән яки бирелгән җир кишәрлеге схемасын раслау турында карар кабул иткәнчегә кадәр яисә күрсәтелгән схеманы раслаудан баш тарту турында карар кабул ителгәнчегә кадәр, дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылып торыла.

3.7.1.2. Бүлек белгече туктатып тору өчен әлеге Регламентның 3.8.1.1 пунктында күрсәтелгән нигезләрне тикшереп чыга. Туктатып тору өчен нигезләр Бүлек белгече туктатып тору турында карар проекты әзерли һәм туктатып тору турында карар проектын килештерү өчен Бүлек мөдиренә, Министрлыкның Җир песурслары белән идарә башлыгына (алга таба – Идарә) юллый.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек мөдире, Идарә башлыгы белән килештерелгән туктатып тору турында карар проекты.

3.7.1.3. Бүлек белгече Бүлек мөдире, Идарә башлыгы белән килештерелгән туктатып тору турында карар проектын имзалау өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзалау өчен министрның беренче урынбасарына юлланган туктатып тору турында карар проекты.

3.7.1.4. Министрның беренче урынбасары туктатып тору турында карарга имза куя, имза куелган карар регистрация өчен контроль бүлегенә юллана.

Процедуралар нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасары имза куйган, регистрация өчен контроль бүлегенә юлланган карар.

3.7.1.5. Контроль бүлеге белгече туктатып тору турында карарны регистрацияли, Бүлек белгече туктатып тору турында карарны алу өчен

билгеләнгән вакыт турында хәбәр итә, яки туктатып тору турында карарны гариза бирүче күрсәткән почта яки электрон адреска юллый.

Процедуралар нәтиҗәсе: контроль бүлегендә регистрацияләнгән һәм гариза бирүчегә юлланган туктатып тору турында карар.

Әлеге Регламентның 3.8.1.2 – 3.8.1.5 пунктлары билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар кергәннән соң биш эш көне эчендә үтәлә.

3.7.1.6. Алдарак тапшырылган яки җибәрелгән җир кишәрлеге урнашу схемасын раслау турында карар кабул ителгәч яки күрсәтелгән схеманы раслаудан баш тарту турында карар кабул ителгәч, әлеге Регламентның 3.9 – 3.10 пунктларында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

3.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗы өчен бакчачылык, крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлеге бирелү турында белдерү (алга таба – белдерү) басылып чыкканнан соң 30 календарь көненә туктатылып торыла.

3.7.3. Җир кишәрлеге ясаласы җир кишәрлеге схемасы «Россия Федерациясе Җир Кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге № 137-ФЗ Федераль законның (алга таба - № 137-ФЗ Федераль закон) $3^{5}$ статьясы нигезендә килештерелергә тиеш булган очракларда әлеге Регламентның 2.4.1, 2.4.2 пунктларында каралган срок $3^{18}$ статьясы нигезендә җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында гариза кергән көннән 45 көннән дә артык булмаган срокка кадәр озайтылырга мөмкин.

3.8. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек

3.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында нигезләр булмаса, Бүлек белгече “Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында гариза үтү битен” тутыра (әлеге Регламантка 4 нче кушымта) һәм ведомствоара электрон арадашлык системасы аша электрон формада (техник мөмкинлекләр булмаганда – башка ысуллар белән) әлеге Регламентның 2.6.6 пункты белән каралган документларны һәм мәгълүматны бирү турында запрослар юллый.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат (документлар) бирү турындагы запрослар.

3.8.2. Министрлыкка җир кишәрлеген РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә бирүне алдан килештерү турында гариза керсә, җир кишәрлеге ясаласы җир кишәрлеге схемасы «Россия Федерациясе Җир Кодексын гамәлгә кертү турында» № 137-ФЗ Федераль законның $3^{5}$ статьясы нигезендә килештерелергә тиеш булган очракларда, Бүлек белгече ведомствоара арадашлык систпемасы аша электрон формада территориянең кадастр планында җир кишәрлеге урнашу схемасын

килештерү өчен Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына (алга таба – ТР Урман хуҗалыгы министрлыгы) юллый.

Процедуралар нәтиҗәсе: ТР Урман хуҗалыгы министрлыгына килештерү өчен юлланган территориянең кадастр планында җир кишәрлеге урнашу схемасы.

Әлеге Регламентның 3.8.1 – 3.8.2 пунктлары белән билгеләнгән процедуралар гариза һәм документлар кергәч, бер эш көне эчендә үтәлә.

3.8.3. Ведомствоара арадашлык органнары белгечләре ведомствоара электрон арадашлык системасы аша кергән, әлеге Регламентның 3.8.2 пунктында күрсәтелгән запрослар нигезендә, законнарда билгеләнгән срокларда соралган документларны (мәгълүматны) бирәләр.

Процедуралар нәтиҗәсе: запроска җавап булып торган мәгълүмат, документлар, яисә баш тарту турында Министрлыкка юлланган белдерү кәгазе.

3.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү

3.9.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен әзерләгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе проекты (җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында карар проекты яки җир кишәрлеген милеккә бирү турында карар проекты белән сату-алу шартнамәсен (җир кишәрлеген арендага бирү турында карар проекты белән аренда шартнамәсе)) яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты (җир кишәрлеген бирүгә алдан килешүдән баш тарту турында карар проекты яки җир кишәрлеген милеккә, арендага бирүдән баш тарту турында карар проекты) әзерләнә.

3.9.2. Хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗы өчен бакчачылык, крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлеге бирелү турында белдерү һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту

3.9.2.1. Әлеге Регламентның 3.8.2, 3.8.3 пунктлары нигезендә соралган белешмәләр ТР буенча ФСХИдан, ТР буенча Росреестрдан алынгач һәм ТР Урман хуҗалыгы министрлыгыннан территориянең кадастр планында җир кишәрлеге урнашу схемасын килештерү яки килештерүдән баш тарту алгач (ТР Урман хуҗалыгы министрлыгына территориянең кадастр планында җир кишәрлеге урнашу схемасын юлланган очракта) Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарта торган әлеге Регламентның 2.8.4 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавын тикшерә;

белдерү проекты яки баш тарту нигезләре һәм ачыкланган кимчелекләрне төзәтү тәкъдимнәре күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты (җир кишәрлеген бирүгә алдан килешүдән баш тарту турында

карар проекты яки җир кишәрлеген милеккә, арендага бирүдән баш тарту турында карар проекты) әзерләнә;

белдерү проекты яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты килештерү өчен Бүлек мөдиренә юллана.

Әлеге Регламентның 2.8.4 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең берсе генә булса да, Бүлек белгече дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту проекты әзерли.

Гариза бирүче гаризаны һәм документларны Республика порталы аша электрон рәвештә юллаган булса һәм шул ук вакытта гаризада дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон рәвештә алу күрсәтелсә, Бүлек белгече хокук гамәлдән чыгарылу турында карар проектын яисә баш тарту турында карар проектын электрон рәвештә әзерли.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар юлланган запросларга җаваплар алынгач бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: әзерләнгән һәм килештерү өчен Бүлек мөдиренә юлланган белдерү проекты яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты.

3.9.2.2. Бүлек мөдире белдерү проектын яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын карап чыга, килештерә һәм белдерү проектын яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын килештерү өчен Идарә башлыгына юллый.

Процедура нәтиҗәсе: бүлек мөдире белән килештерелгән һәм килештерү өчен Идарә башлыгына юлланган белдерү проекты яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты.

3.9.2.3. Идарә башлыгы белдерү проектын яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын карап чыга, килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге Регламентның 3.9.2.2, 3.9.2.3 пунктлары билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек мөдире, Идарә башлыгы белән килештерелгән, килештерү өчен Бүлек белгеченә юлланган белдерү проекты яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты.

3.9.2.4. Бүлек белгече Бүлек мөдире, Идарә башлыгы белән килештерелгән белдерү проектын яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын хокукый экспертиза үткәрү өчен хокук идарәсенә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланган көндә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире, Идарә башлыгы белән килештерелгән, хокук идарәсенә юлланган белдерү проекты яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты.

3.9.2.5. Хокук идарәсе белгече белдерү проектына яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектына хокукый экспертиза ясый, килештерелгән белдерү проектын яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты яисә белдерү проектында яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектында кимчелекләр булган очракта хокук идарәсе бәяләмәсе проектын килештерү өчен хокук идарәсе башлыгына юллый.

Процедура нәтиҗәсе: хокук идарәсе белгече белән килештерелгән, белдерү проекты яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты яисә белдерү проектында яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектында кимчелекләр булган очракта хокук идарәсе бәяләмәсе проекты.

3.9.2.6. Хокук идарәсе башлыгы белдерү проекты яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты буенча хокук идарәсе бәяләмәсенә кул куя яисә белдерү проектын яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге Регламентның 3.9.2.5, 3.9.2.6 пунктлары билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: белдерү проекты яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты буенча хокук идарәсе бәяләмәсе яисә килештерелгән белдерү проекты яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты.

3.9.2.7 Бүлек белгече хокук идарәсе бәяләмәсен алган очракта кимчелекләрне төзәтә һәм белдерү проектын яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын кабаттан килештерергә дип Хокук идарәсе башлыгына юллый.

Процедура нәтиҗәсе: хокук идарәсе төзәтмәләрен искә алып эшләнгән, килештерү өчен хокук идарәсе башлыгына юлланган белдерү проекты яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты.

3.9.2.8 Хокук идарәсе башлыгы хокук идарәсе бәяләмәсендә күрсәтелгән кимчелекләрнең төзәтелү фактын тикшерә һәм тиешле проектны килештерә.

Әлеге Регламентның 3.9.2.7 һәм 3.9.2.8 пунктлары билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән белдерү проекты яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты.

3.9.2.9. Бүлек белгече белдерү проектын яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты белән бергә юллана торган хатны кул куйдыру өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасарына юлланган белдерү проекты яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты.

3.9.2.10. Министрның беренче урынбасары документларга кул куя һәм имзаланган белдерүне Бүлек белгеченә яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карарны регистрацияләү өчен контроль бүлегенә юллый.

Гаризада хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон формада алу күрсәтелгән булса, министрның беренче урынбасары электрон документ формасындагы дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карарны проектына, бергә юллана торган хатка көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куя.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Министрның беренче урынбасары кул куйган һәм Бүлек белгеченә юлланган белдерү, регистрация өчен эш башкару бүлегенә юлланган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар.

3.9.2.11. Министрның беренче урынбасары белдерүгә кул куйгач Бүлек белгече:

белдерүне Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән рәсми сайтка (http://www.torgi.gov.ru), шулай ук, Министрлыкның «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәрендәге рәсми сайтына урнаштыра һәм тиешле тәртиптә басылуын тәэмин итә;

гариза бирүчегә ул күрсәткән почта яки электрон адресы буенча белдерү басылуы турында һәм башка гражданнардан, крестьян (фермер) хуҗалыкларыннан күрсәтелгән максатларда җир кишәрлеге бирү буенча аукционда катнашу нияте турында гаризалар кергән периодта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында хәбәр юллый.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: бастырылган белдерү яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар.

3.9.3. Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында карар проекты яки җир кишәрлеген милеккә, арендага бирү турында Министрлык карары проекты һәм сату-алу шартнамәсе проекты, аренда шартнамәсе проекты яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту проекты әзерләү.

3.9.3.1. Белдерү басылганнан соң утыз көн эчендә башка гражданнардан, крестьян (фермер) хуҗалыкларыннан аукционда катнашу нияте турында гариза кермәсә, Бүлек белгече:

1) җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында Министрлык карары проекты әзерли - Министрлыкка җир кишәрлеген РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә бирүне алдан килештерү турында гариза керсә;

2) җир кишәрлеген милеккә, арендага бирү турында Министрлык карары проекты һәм сату-алу шартнамәсе проекты, аренда шартнамәсе проекты әзерли - Министрлыкка дәүләт хезмәтендә каралган максатларда РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә җир кишәрлеген милеккә, арендага бирү килештерү турында гариза керсә.

Белдерү басылганнан соң утыз көн эчендә башка гражданнардан, крестьян (фермер) хуҗалыкларыннан аукционда катнашу нияте турында гариза кергән очракта, Бүлек белгече дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты әзерли:

1) җир кишәрлеген бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән затка аукцион үткәрмичә җир кишәрлеген бирүдән баш тарту турында;

2) җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән затка җир кишәрлеген бирүне алдан килештерүдән баш тарту турында.

Бу пункт билгели торган процедуралар башка гражданнардан, крестьян (фермер) хуҗалыкларыннан аукционга катнашу нияте турында гариза кабул ителү срогы тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: әзерләнгән җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында министрлык карары проекты яки җир кишәрлеген милеккә, арендага бирү турында Министрлык карары проекты һәм сату-алу шартнамәсе проекты, аренда шартнамәсе проекты яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту проекты.

3.9.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты белән бер үк вакытта башка гражданнардан, крестьян (фермер) хуҗалыкларыннан аукционга катнашу нияте турында гаризалар кабул ителгән очракта, Бүлек белгече җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турындагы гаризада яисә җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән максатларда җир кишәрлеген сату буенча аукцион үткәрү турында яки җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе төзү хокукына аукцион үткәрү турында Министрлык карары проектын әзерли.

Бу пункт билгели торган процедуралар башка гражданнардан, крестьян (фермер) хуҗалыкларыннан аукционга катнашу нияте турында гариза кабул ителү срогы тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турындагы гаризада яисә җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән максатларда җир кишәрлеген сату буенча аукцион үткәрү турында яки җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе төзү хокукына аукцион үткәрү турында Министрлык карары проекты.

3.9.3.3. Бүлек белгече әлеге Регламентның 3.9.2.1 – 3.9.2.10 пунктларында билгеләнгән тәртиптә имзалануны тәэмин итә:

җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында Министрлык карары проекты - Министрлыкка җир кишәрлеген РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә бирүне алдан килештерү турында гариза керсә;

җир кишәрлеген милеккә, арендага бирү турында Министрлык карары проекты һәм сату-алу шартнамәсе проекты, аренда шартнамәсе проекты - Министрлыкка дәүләт хезмәтендә каралган максатларда РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә җир кишәрлеген милеккә, арендага бирү килештерү турында гариза керсә.

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты һәм җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турындагы гаризада яисә җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән максатларда җир кишәрлеген сату буенча аукцион үткәрү турында яки җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе төзү хокукына аукцион үткәрү турында Министрлык карары проекты.

Җир кишәрлеген милеккә бирү турындагы карар министр тарафыннан имзалана.

Әлеге Регламентның 3.9.2.1 – 3.9.2.10 пунктлары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган процедуралар документлар Бүлек мөдиренә юлланган соң өч эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе:

Министрның беренче урынбасары тарафыннан имзаланган һәм контроль бүлегенә регистрация өчен юлланган җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында карар яисә җир кишәрлеген милеккә, арендага бирү турында карар, аренда шартнамәсе яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар белән аукцион үткәрү турында карар (җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турындагы гаризада яисә җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән максатларда җир кишәрлеген сату буенча аукцион үткәрү турында яки җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе төзү хокукына аукцион);

Министр кул куйган һәм контроль бүлегенә регистрация өчен юлланган җир кишәрлеген милеккә бирү турында карар һәм министрның беренче урынбасары кул куйган сату-алу шартнамәсе.

Гаризада хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон формада алу күрсәтелгән очракта министр җир кишәрлеген милеккә бирү турында карарны, министрның

беренче урынбасары җир кишәрлеген арендага бирү турында карарны, аренда шартнамәсе проектын яки сату-алу шартнамәсе проектын, аренда шартнамәсе проектына яки сату-алу шартнамәсе проектына кушып җибәрелә торган хатны электрон формада көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалый.

3.10. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

3.10.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе гариза бирүчегә үзе сайланган ысул белән бирелә (җибәрелә):

гариза бирүченең үз кулына Министрлыкта язмача яки гариза бирүче яшәгән яки торган урынга почта аша; электрон почта һәм (яки) Республика порталындагы шәхси кабинетка электрон документ формасында.

Гариза бирүченең теләге буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе МФЦ аша МФЦ регламентына туры китереп, Министрлыктан җибәрелгән электрон документ экземпляры формасында алынырга мөмкин, документ кәгазьгә чыгарылып, МФЦ мөһере басыла һәм МФЦ хезмәткәре имзасы куела.

3.10.2. Административ процедуралар башкаруны башлау өчен нигез булып контроль бүлеге белгеченең дәүләт хезмәте күрсәтүне раслаучы документны (җир кишәрлеген милеккә, арендага бирү турында карар) яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карарны алуы тора.

Контроль бүлеге белгече дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә регистрация үткәрә.

Бүлек белгече:

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турындагы мәгълүматны дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмати системасының документацияләр алып бару подсистемасына кертә;

гариза бирүчегә (аның вәкиленә) Республика порталы аша электрон арадашлык юлы белән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен МФЦдан алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Процедуралар техник мөмкинлек булганда дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмати системасыны кулланып автомат режимда башкарыла.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслаган документка имза куелган көндә башкарыла.

Административ процедуралар башкарылу нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүматны мәгълүмат системаларына урнаштыру, гариза бирүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында хәбәр итү.

3.10.3. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алырга МФЦга мөрәҗәгать итсә, МФЦ хезмәткәре гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документның кәгазь экземпляры рәвешендә тапшыра. Гариза

бирүче соравы буенча электрон документның кәгазь экземпляры белән бергә электрон документның экземпляры күчергечкә яздырып бирелергә мөмкин.

Бу пункт билгели торган процедуралар МФЦның эш регламенты белән билгеләнгән срокларда гариза бирүче килгәч чират тәртибендә башкарыла.

3.10.4. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алырга Республика порталы ашы мөрәҗәгать итсә, шәхси кабинетка автомат рәвештә министрның яки министрның беренче урынбасарының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның электрон образы җибәрелә.

Бу пункт билгели торган процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтүне раслаган (хезмәт күрсәтүдән баш тарткан) документка министр, министрның беренче урынбасары кул куйган көнне башкарыла.

Административ процедуралар башкарылу нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүне раслаган документны яки, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуны, Республика порталын кулланып гариза бирүчегә җибәрү (тапшыру).

3.10.5. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алырга килгән очракта, контроль бүлегенең документларны бирүгә җаваплы белгече түбәндәгеләрне башкара:

гариза бирүченең шәхесен ачыклый, шәхесен раслаган документны тикшерә;

вәкилнең вәкаләтләрен тикшерә (боерык, ышанычнамә һ.б.);

гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен бирә һәм исәп-хисап кенәгәсенә документлар тапшырылу турында язып куя;

Әлеге пункт билгели торган процедура гариза бирүче килгән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе (гариза бирүчегә бирелгән җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында карар яисә җир кишәрлеген милеккә, арендага бирү турында карар, аренда шартнамәсе яки җир кишәрлеген милеккә, арендага бирүдән баш тарту турында, җир кишәрлеге бирүне алдан килештерүдән баш тарту турында карар).

3.10.5. Гариза бирүче җир кишәрлеген сату-алу шартнамәсен, аренда шартнамәсен алганнан соң утыз календарь көненнән дә артыграк булмаган вакытта аларны имзалый һәм Министрлыкка тапшыра.

3.10.6. Министрның беренче урынбасары һәм гариза бирүче кул куйган җир кишәрлеген сату-алу шартнамәсе, аренда шартнамәсе Министрлыкның Исәп-хисап һәм чараларны гамәлгә ашыру идарәсенең Татарстан Республикасы дәүләт милке реестры бүлегендә регистрацияләнә һәм гариза бирүчегә җибәрелә.

Әлеге пункт билгеләгән процедура гариза алдагы процедура тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: регистрацияләнгән һәм гариза бирүчегә юлланган җир кишәрлеген сату-алу, аренда шартнамәсе.

3.11. Гариза бирүчедән өстәмә мәгълүмат алу

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында гариза бирүчедән нинди дә булса өстәмә документлар һәм (яисә) мәгълүмат алу каралмаган.

3.12. Дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсе булган документларда киткән ялгышларны һәм хаталарны (алга таба – техник хата) төзәтү

3.12.1. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында карарда яки җир кишәрлеген сату-алу, аренда шартнамәсендә техник хатаны төзәтү буенча мөрәҗәгате техник хатаның төзәтелүенә нигез булып тора.

Техник хатаны электрон формада һәм МФЦ аша башкарылмый.

3.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата табылганда гариза бирүче түбәндәгеләрне Министрлыкка юллый:

техник хаталарны төзәтү турында гариза (әлеге Регламентка 5 нче кушымта);

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хата булган документ;

техник хатаның булуын дәлилләгән юридик көчкә ия документлар.

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган документтагы мәгълүматта булган техник хатаны төзәтү турында гариза гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән яки почта аша тапшырыла.

3.12.3. Контроль бүлеге белгече беркетелгән документлары белән бергә техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итеп ала да, регистрацияләп Бүлек белгеченә бирә.

Әлеге пункт билгеләгән процедура гариза регистрацияләнгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм рәсмиләштерелгән гаризаның карау өчен Бүлек белгеченә юллануы.

3.12.4. Бүлек белгече документларны карый да, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтүләр кертү максатыннан әлеге Регламентның 3.9.3 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра, гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкиленә) имза куйдырып шәхсән үзенә төзәтелгән документны тапшыра, гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хата булган төп нөсхәне ала, яки гариза бирүче адресына почта аша (электрон почта аша) Министрлыкка техник хата булган документның төп нөсхәсен китереп документны алу мөмкинлеге турында хат юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура техник хата табылганнан соң яки теләсә кайсы катнашы булган затның хата турындагы мөрәҗәгатеннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: яңадан формалаштырылган, гариза бирүчегә тапшырылган (юлланган) документ.

3.12.5. Техник хатаны төзәтүгә кагылышлы документлар (теркәлгән документлары белән бергә техник хатаны төзәтү турында гариза, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә кертелгән үзгәрешләр (техник хатаны төзәтү белән бергә) Министрлыкта саклаган документ нөсхәсенә беркетелә).

3.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документ дубликатын бирү

3.13.1. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны бозса яки югалтса, Министрлыкка документның дубликатын сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Министрлыкка дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның дубликатын бирү турында министр исеменә ирекле формада дубликат бирү сәбәпләрен күрсәтеп язылган гариза керү дубликатны бирү процедурасын башлау өчен нигез булып тора.

Дубликат бирү электрон формада һәм МФЦ аша башкарылмый.

3.13.2. Министрлыкка кергән гариза регистрация өчен җаваплы Министрлыкның контроль бүлеге хезмәткәре тарафыннан кергән көнне регистрацияләнә һәм бер эш көнендә карап чыгу өчен министрның беренче урынбасарына тапшырыла.

Министрның беренче урынбасары гаризаны бер эш көне эчендә карап чыга һәм башкару өчен Бүлек мөдиренә бирә. Бүлек хезмәткәре ике эш көне эчендә шул ук регистрация номеры һәм датасы белән документның дубликатын әзерли, өстәге почмагына «ДУБЛИКАТ» дип языла, документның әзер дубликаты имза белән гариза бирүченең кулына тапшырыла яки гариза бирүче күрсәткән адрес буенча белдерүле заказлы хат белән почта аша юллана.

Процедураның нәтиҗәсе булып дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документның дубликаты тора.

## 4. Администатив регламентның үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр куючы башка норматив хокукый актларның үтәлешен һәм башкарылуын, шулай ук, алар кабул иткән карарларны дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Идарә (бүлек) җитәкчеләре әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәү һәм башкаруны тикшерү юлы белән контрольдә тота.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне Министрлыкның вазыйфаи затлары контрольдә тота. Контрольдә тотучы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык идарәләре (бүлекләре) турында нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

4.3. Агымдагы контроль Министрлыкның вазыйфаи затларының әлеге Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгеләүче башка норматив хокукый актларның үтәвен тикшереп тору юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контроль даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүне, гариза бирүчеләрнең дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затларның кылган (кылмаган) гамәлләре турында шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләрен карап, карарлар кабул итүне һәм гариза бирүченең мөрәҗәгатенә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

канцелярия эшләрен алып бару;

документлар карау нәтиҗәләренең закон таләпләренә (әлеге Регламентка) туры килүе;

документлар кабул итү срокларын һәм тәртибен саклау;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләрне тапшыру срогы һәм тәртибе саклану.

Тикшерүләр үткәрү планлы (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең мөрәҗәгате буенча) булырга мөмкин.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү буенча планнан тыш тикшерү карары түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламент таләпләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актларны бозу очраклары алдарак ачыкланып, аларның төзәтелүен тикшерү өчен;

2) Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының үз гамәлләре белән (гамәл кылмаулары белән) аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозулары турында гариза бирүчеләрнең зарланып мөрәҗәгать итү очрагында.

4.6. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту Министрлык эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдәге ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәгенең, № 210-ФЗ Федераль законның 16 статьясының 1[1] кисәгендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук, аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләр Министрлыкның, Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата Министрлыкка шикаять белдерә ала.

Министрның дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә

МФЦ хезмәткәренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата шикаять МФЦ җитәкчесенә бирелә.

МФЦның кылган (кылмаган) гамәлләренә карата шикаять МФЦны гамәлгә куючыга ( (алга таба – МФЦны гамәлгә куючы) бирелә.

5.2. Гариза бирүче түбәндәге очракларда да шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар яки мәгълүмат, яки гамәлләр кылуны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты, МФЦ, МФЦның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы

ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогы яки тәртибе бозылганда;

9) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының законнарында һәм башка норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган булып та, дәүләт хезмәтү күрсәтү туктатып торылса;

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән беренче тапкыр кабул иткәндә юклыгы яки дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән, дәүләт хезмәте күрсәткәндә яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны яки мәгълүматны таләп итү, № 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пункты искәрмә булып тора.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, МФЦ аша, «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

МФЦның, МФЦ хезмәткәренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата шикаять почта аша, «Интернет» челтәрен файдаланып, МФЦның рәсми сайты аша, Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче органның атамасы, органның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи заты яки дәүләт хезмәткәре, аның җитәкчесе һәм (яки) хезмәткәре;

2) гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат, мөрәҗәгать итүче юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең, МФЦның шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында мәгълүмат;

4) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләре.

5.5. Шикаятькә анда бәян ителгәннәрне раслый торган документларның күчермәләре беркетелә ала.

5.6. Шикаять ул кергән эш көненнән соңгы көннән дә калмыйча регистрацияләнә.

Шикаять регистрацияләнгәннән соң унбиш көн эчендә карала, ә Министрлыкның гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан баш тартуга яки ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.7 Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Министрлык тарафыннан җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.8. Бу Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм, гариза бирүченең теләгенә карап, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип табылса, бу Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ясалган кимчелекләрне төзәтү өчен Министрлык кылачак гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук килеп туган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен гариза бирүче кылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерелмәсә, бу Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта гариза бирүчегә кабул ителгән карар турында дәлилле аңлатма бирелә, кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе бәян ителә.

5.11. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча, административ хокук бозу билгеләре яки җинаять ачыкланса, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны тиз арада прокуратура органнарына юллый.

5.12. Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, яисә дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерүгә бәйле мөнәсәбәтләр № 210-ФЗ Федераль закон нигезендә көйләнә.

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмчел хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) эшчәнлеге алып бару өчен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына
1 нче кушымта

Тәкъдим ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына
______________________________________

______________________________________
(физик затлар өчен - фамилия, исем, әтисе исеме (булса), яшәү урыны, шәхесне таныклаучы документ реквизитлары, ИНН)
______________________________________
(юридик затлар өчен - атамасы, урнашу урыны, оешу-хокукый формасы, ЕГРЮЛда дәүләт теркәве узуы турында белешмә, ОГРН)
______________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

## РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында гариза

____________________________________________нигезендә,
(п.2 ст.39.3, п.2 ст.39.6 белән каралган нигезләр арасыннан күрсәтелә).
______________________________________________________
(җир кишәрлеген файдалану максаты күрсәтелә)
__________ кв.м. мәйданлы җир кишәрлеген, кадастр номеры ________:___, рөхсәт ителгән файдалану төре __________________, ______________җир категориясеннән, урнашкан адресы:
______________________________________________________
(җир кишәрлегенең урнашу урыны күрсәтелә
______________________________________________________
җир кишәрлеген бирүне алдан килештерүегезне үтенәм.
(гариза бирүче җир кишәрлеген алырга теләгән хокук төре)
Өстәмә мәгълүмат (түбәндәге шартлар булганда тутырыла):
______________________________________________________
җир кишәрлеге дәүләти яки муниципаль ихтыяҗ өчен тартып алынган җир кишәрлеге урынына бирелсә, җир кишәрлеген дәүләти яки муниципаль ихтыяҗ өчен тартып алу турында карар реквизитлары;
______________________________________________________
җир кишәрлеге әлеге документта һәм (яки) проектта каралган объектларны урнаштыру өчен бирелсә, территориаль планировка документын һәм (яки) территорияне планлаштыру проектын раслау турында карар реквизитлары;
______________________________________________________

соралган җир кишәрлеген күрсәтелгән проект белән ясау каралса, территорияне ызанлау проектын раслау турында карар реквизитлары

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен:
- җибәрергә ______________________________________________________;
(күрсәтелә: электрон документ формасында МФЦга, электрон документ экземплярлы рәвешендә кәгазьдә; Республика порталында шәхси кабинетка);
- Министрлыкка бирергә ______________________
_________________________________________________________________.
(күрсәтелә: кәгазь документ формасында, электрон документ формасында яки электрон документ экземплярлы рәвешендә кәгазьдә)

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында телефон аша уздырылган сораштыруда телефон аша катнашырга ризалыгымны бирәм: ________________________.

Гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) (ышанычнамә буенча вәкиләнең (вәкилләрнең) имзасы ____
№_________________________
________________________________________/________________________/
(вәкилнең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булса), имза)

М.П.(мөһер булса)

Мөрәҗәгать кабул итеп алынды: "___"__________ 20__ г.
_______/___________________/имза, мөрәҗәгатьне кабул иткән белгечнең фамилиясе, инициаллары

Җир кишәрлеге бирүне
алдан килештерү турында
гаризага кушымта

Җир кишәрлеге бирүне
алдан килештерү гаризасына теркәлгән документлар исемлеге

| Документ атамасы | Бит саны |
|---|---|
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |

Гариза бирүче (ышанычнамә буенча вәкил)
_______________________________________

_________________________________
(фамилия, инициаллар) (имза)

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белгече
_________________________________ _____________________________
(фамилия, инициаллар) (имза)
Барлык документлар 1 данәдә бирелә.

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмчел хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) эшчәнлеге алып бару өчен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына
2 нче кушымта

Тәкъдим ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына
________________________________________

________________________________________
(физик затлар өчен - фамилия, исем, әтисе исеме (булса), яшәү урыны, шәхесне таныклаучы документ реквизитлары, ИНН)

________________________________________
(юридик затлар өчен - атамасы, урнашу урыны, оешу-хокукый формасы, ЕГРЮЛда дәүләт теркәве узуы турында белешмә, ОГРН)

________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә җир кишәрлеген милеккә, арендага бирү турында гариза

__________________________________________ нигезендә
________________________________________________________________________
(п.2 ст.$39^{3}$, п.2 ст.$39^{6}$ ЗК РФ белән каралган нигезләр арасыннан күрсәтелә)
________________________________________________________________________
(җир кишәрлеген файдалану максаты күрсәтелә)
___________ кв.м. мәйданлы җир кишәрлеген, кадастр номеры ________:___, рөхсәт ителгән файдалану төре ____________________, ________________җир категориясеннән, урнашкан адресы:
________________________________________________________________________
(җир кишәрлегенең урнашу урыны күрсәтелә

_____ (гариза бирүче җир кишәрлеген алырга теләгән хокук төре)
________________________________________________________________ җир кишәрлеген милеккә, ____________ срокка арендага бирүегезне (кирәгенең астына сызарга) үтенәм.

Өстәмә мәгълүмат (түбәндәге шартлар булганда тутырыла):
________________________________________________________________________
җир кишәрлеге дәүләт ихтыяҗы өчен тартып алынган җир кишәрлеге урынына бирелсә, җир кишәрлеген дәүләт ихтыяҗы өчен тартып алу турында карар реквизитлары;

___

Соралган җир кишәрлеге ясалган булса яки аның чикләре әлеге карар нигезендә ачыкланган булса, җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында карар реквизитлары;

___

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен:

- җибәрергә ___;

(күрсәтелә: электрон документ формасында МФЦга, электрон документ экземпляры рәвешендә кәгазьдә; Республика порталында шәхси кабинетка);

- Министрлыкка бирергә ___

___.

(күрсәтелә: кәгазь документ формасында, электрон документ формасында яки электрон документ экземплярлары рәвешендә кәгазьдә)

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында телефон аша уздырылган сораштыруда телефон аша катнашырга ризалыгымны бирәм: ___.

Гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) (ышанычнамә буенча вәкиләнең (вәкилләрнең) имзасы ____ №_______

___/___/

(вәкилнең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булса), имза)

М.П.(мөһер булса)

Мөрәҗәгать кабул итеп алынды: "___"__________ 20__ г.

_______/___________________/имза, мөрәҗәгатьне кабул иткән белгечнең фамилиясе, инициаллары

Җир кишәрлеге
бирү турында
гаризага кушымта

Җир кишәрлеге бирү турында гаризага теркәлгән документлар исемлеге

| Документның атамасы | Битләр саны |
| --- | --- |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |

Гариза бирүче (ышанычнамә буенча вәкил)
________________________________________
__________________________________
(фамилия, инициаллар) (имза)

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белгече
__________________________________ ______________________________
(фамилия, инициаллар) (имза)
Барлык документлар 1 данәдә бирелә.

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмчел хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) эшчәнлеге алып бару өчен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына
3 нче кушымта

Җир кишәрлеген милеккә, арендага бирүдән баш тарту өчен нигезләр

1) Җир кишәрлеге бирү турында гариза белән җир законнары буенча җир кишәрлеген сатулашулар үткәрмичә алу хокукы булмаган зат мөрәҗәгать итә;

2) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлеккә мирас ителгән биләмәләр яки аренда хокукында бирелгән; җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге хокуклары булган кеше мөрәҗәгать итүе яисә җир кишәрлеге бирү турында гаризаның РФ ҖКның $39^{10}$ статьясының 2 пункты 10 подпунктына туры китереп бирелгән булуы чыгарма булып тора.

3) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге яшелчәчелек яки бакчачылык коммерциячел булмаган ширкәтенә бирелгән җирне бүлеп ясалган; әлеге коммерциячел булмаган ширкәтнең әгъзасы (әлеге җир кишәрлеге бакча яки яшелчә җире булса) яисә, гражданнар үз ихтыяҗлары өчен яшелчәчелек яки бакчачалык эше алып барган территория чигендәге җир кишәрлекләренең милек иясе (җир кишәрлеге гомуми файдаланыла торган милеккә кергән очракта) мөрәҗәгать иткән очраклар чыгарма булып тора;

4) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегендә гражданнарга яки юридик затларга караган биналар, корылмалар, төзелеп бетмәгән объектлар урнашкан; корылма (шул исәптән, төзелеп бетмәгән корылма) җир кишәрлегендә сервитут, гаммәви сервитут шартларында, яки РФ ҖКның $39^{36}$ статьясы нигезендә урнашкан объектлар урнашкан очраклар яисә җир кишәрлеген үзенә бирү турындагы гариза белән әлеге бинаның, корылманың, төзелеп бетмәгән объектның хосусый милек иясе мөрәҗәгать иткән очраклар, шулай ук, җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән һәм әлеге җир кишәрлегендә үзбелдекле төзелгән бинаны, корылманы, төзелеп бетмәгән объектны сүтү турында, яки үзбелдекле төзелешне сүтү яисә билгеләнгән срокларда билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында кабул ителгән карар һәм Россия Федерациясенең Шәһәр

төзелеше кодексының $55^{32}$ статьясының 11 өлеше үтәлмәгән очраклар чыгарма булып тора;

5) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегендә дәүләт яки муниципаль милек булган бина, корылма, төзелеп бетмәгән объект урнашкан булса, әлеге җир кишәрлегендә урнашкан корылмаларның (шул исәптән, төзелеп бетмәгән корылмаларның) җир кишәрлегендә урнашуы сервитут шартларында, гаммәви сервитут шартларында рөхсәт ителсә яки РФ ҖК $39^{36}$ статьясына туры китереп урнаштырылган объектлар булса, яки җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгать белән әлеге бина, корылма, алардагы бүлмәләрнең, әлеге төзелеп бетмәгән объектның хокук иясенең чыгуы чыгарма булып тора;

6) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге әйләнештән алынган булса яисә әйләнеше чикләнгән булып, җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән хокук буенча бирергә ярамый;

7) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләти яки муниципаль ихтыяҗларда резервка куелган булып, гариза бирүче җир кишәрлеген милек итеп даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга яисә җир кишәрлеген арендага җир кишәрлеген резервка кую турында карар гамәлдә булганнан озаграк вакытка түләүсез файдалануга бирү турында мөрәҗәгать итсә; җир кишәрлеген резервка кую максатыннан бирү чыгарма булып тора;

8) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге төзелгән территориянең үсеше турында башка зат белән шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан; җир кишәрлеген үзенә бирү турындагы гариза белән шушы җир кишәрлегендә урнашкан бинаның, корылманың, төзелеп бетмәгән объектның хосусый милек иясе яки әлеге җир кишәрлегенә хокукы булган зат мөрәҗәгать иткән очраклар чыгарма булып тора;

9) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге төзелгән территориянең үсеше турында башка зат белән шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан, яисә җир кишәрлеге башка зат белән территорияне комплексլы үзләштерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән ясалган; җир кишәрлеге федераль әһәмияткә ия объектлар, региональ әһәмияткә ия объектлар яки җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыруга билгеләнгән булып, җир кишәрлеген бирү турында әлеге объектларны төзергә вәкаләтле затның мөрәҗәгате чыгарма булып тора;

10) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге башка зат белән территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә яисә төзелгән территориянең үсеше турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән ясалган һәм территориянең планы буенча расланган документациягә ярашлы рәвештә федераль әһәмияткә ия объектлар, региональ

әһәмияткә ия объектлар яки җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыруга билгеләнгән; җир кишәрлеген арендага алу турында гариза белән территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә яисә төзелгән территориянең үсеше турында шартнамә төзелгән һәм әлеге объектларны төзү йөкләмәсе булган затның мөрәҗәгать итүе чыгарма булып тора;

11) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге аукцион предметы булып тора, аны үткәрү турында белдерү Россия Федерациясе Җир Кодексының $39^{11}$ статьясының 19 пунктына туры китереп урнаштырылган;

12) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата аны сату турында аукцион яки әлеге җир кишәрлеге Россия Федерациясе Җир Кодексының $39^{11}$ статьясының 4 пункты 4 подпунктына туры китереп ясалган булса, аны арендалауга шартнамә төзү хокукына аукцион үткәрү турында Россия Федерациясе Җир Кодексының $39^{11}$ статьясының 4 пункты 6 подпункты белән каралган гариза кергән һәм вәкаләтле орган тарафыннан әлеге аукционны үткәрүдән баш тарту турында $39^{11}$ статьясының 8 пунктында каралган нигезләр буенча карар кабул ителмәгән;

13) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата Россия Федерациясе Җир Кодексының $39^{18}$ статьясының 1 пункты 1 подпунктына туры китереп җир кишәрлеген шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яки крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлегенә бирү турында белдерү басылган;

14) җир кишәрлеген куллану рөхсәте җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән максатларга туры килми; территорияне планлаштыруның расланган проектына туры китереп линияле объект урнаштыру чыгарма булып тора;

15) соралган җир кишәрлеге тулысынча территорияне куллануның аерым шартлары булган зона чикләрендә урнашкан, биредә җир кишәрлекләрен куллануның билгеләнгән чикләре җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеген куллану максатларына туры килми;

16) соралган җир кишәрлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә расланган оборона һәм иминлек ихтыяҗларында бирелгән һәм вакытлыча күрсәтелгән ихтыяҗларда кулланылмый торган җир кишәрлекләре исемлегенә кертелмәгән, җир кишәрлеген бирү турында гариза Россия Федерациясе Җир Кодексының $39^{10}$ статьясының 2 пункты 10 подпунктына туры китереп бирелгән очракларга карый;

17) җир кишәрлеген коммерцияләшмәгән бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтенә бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы

Россия Федерациясе Җир Кодексының 39[18] статьясының 6 пунктын белән билгеләнгән үлчәмне артып китә;

18) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территориаль планировка документлары һәм (яки) территорияне планировкалау документациясе буенча федераль әһәмияткә ия объектлар, региональ әһәмияткә ия объектлар яки җирле әһәмияткә ия объектлар урнаштыру билгеләнгән һәм җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге объектларны төзү өчен вәкаләтләре булмаган зат мөрәҗәгать иткән;

19) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге Россия Федерациясе дәүләт программасы, Татарстан Республикасы дәүләт программасы буенча биналар һәм корылмалар салу өчен билгеләнгән һәм җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге биналарны, корылмаларны төзү өчен вәкаләтләре булмаган зат мөрәҗәгать иткән;

20) җир кишәрлеген белдерелгән хокукларда бирү рөхсәт ителми;

21) гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеген ничек куллану рөхсәт ителүе билгеләнмәгән;

22) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелеп соралган җир кишәрлеге җирләрнең билгеле категорияләренә кертелмәгән;

23) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелеп соралган җир кишәрлеге бирү буенча алдан килештерелгән карар кабул ителгән, аны гамәлдә булу вакыты чыкмаган, ә җир кишәрлеген бирү турында әлеге карарда күрсәтелмәгән зат мөрәҗәгать иткән булса;

24) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алынган һәм гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеген бирү максатлары әлеге җир алынган максатларга туры килми; әлеге җир кишәрлегендә урнашкан күпфатирлы йорт тузган һәм сүтелергә яисә төзекләндерелергә тиеш дип танылу сәбәпле, җир кишәрлеге дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алынган булу чыгарма булып тора;

25) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең чикләре «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге № 218-ФЗ Федераль законга туры китереп төгәлләштерелергә тиеш;

26) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы җир кишәрлегенең урнашу схемасына, территорияләрне ызанлау проектына яки урман кишәрлекләренең проект документацмясенә туры китереп ясалган булса да, аларда күрсәтелгәннән ун проценттан да күбрәккә артып китә;

27) «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлык үсеше турында» 2007 елның 24 июлендәге № 209-ФЗ Федераль законның 18 статьясының 4 кисәгендә каралган дәүләт милке исемлегенә яисә муниципаль милек исемлегенә кертелгән җир кишәрлеген бирү турында гариза белән кече яки урта эшкуарлык субъекты булмаган зат яки күрсәтелгән Федераль законның 14 статьясы 3 кисәге нигезендә ярдәм күрсәтелә алмый торган зат мөрәҗәгать итә.

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмчел хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) эшчәнлеге алып бару өчен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына
4 нче кушымта

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында гаризаның үтү бите

Гариза бирүче ______________________________________________
Регистрация (керү) номеры __________________________

| № п/п | Министрлык бүлекләре | Алу датасы | Имза | Тапшыру датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге белгече | | | | |
| 2. | Контроль бүлеге | | | | |
| 3. | Дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге белгече | | | | |
| | Килештерүләр: | | | | |
| 4. | Дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге мөдире | | | | |
| 5. | Җир ресурслары идарәсе башлыгы | | | | |
| 6. | Хокук идарәсе башлыгы | | | | |
| 7. | Хокук идарәсе белгече | | | | |
| 8. | Хокук идарәсе башлыгы | | | | |
| 9. | Министрның беренче урынбасарының кабул итү бүлмәсе (документларны килештерү һәм имзалау) | | | | |
| 10. | Контроль бүлеге (документларны формалаштыру һәм регистрацияләү) | | | | |

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмчел хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) эшчәнлеге алып бару өчен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына
5 нче кушымта

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт
мөнәсәбәтләре министрына

# Техник хатаны төзәтү турында
# гариза

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмчел хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) эшчәнлеге алып бару өчен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә киткән хата турында хәбәр итәм

Язылган:______________________________________________________________
______________________________________________________________________

Дөрес мәгълүмат:______________________________________________________
______________________________________________________________________

Техник хатаны төзәтүегезне һәм «____»__________ 20______ел ________ номерлы карарга тиешле үзгәрешләр кертүегезне үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:
1.
2.
3.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) мәгълүматны
_______________________________________________________
_______________________________________________алырга ризалыгымны бирәм.
(кәгазь документ формасында, электрон документ формасында, Бердәм портал, Республика порталындагы шәхси кабинетка)

______________ ________________ ( ________________)
(дата) (имза) (Ф.И.ӘИ. (соңгышысы булса))

М.П. (мөһер булса)

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмчел хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) эшчәнлеге алып бару өчен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына
кушымта (белешмәлек)

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча җаваплы һәм аның башкарылуын контрольдә тотучы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмә

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 221-40-00 | mzio@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары | 221-40-01 | mzio@tatar.ru |
| Җир ресурслары идарәсе башлыгы | 221-40-75 | NV.Zaharova@tatar.ru |
| Дәүләт җирләрен нәтиҗәле файдалану бүлеге мөдире | 221-40-34 | YP.Biktimirova@tatar.ru |
| Контроль бүлеге мөдире | 221-40-81<br>221-40-83 | Gulnur.Rumyanceva@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты
Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе башлыгы | 264-76-89 | Lenar.Fatterahmanov@tatar.ru |